КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 ноябрь г.Казань № 1418

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда туристлык тармагының кадрлар потенциалын үстерү үзәген төзүгә һәм «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенә һөнәри әзерлек программалары буенча укытуга субсидия рәвешендә грант бирү турында» 2023 ел, 23 август, 1008 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елда туристлык тармагының кадрлар потенциалын үстерү үзәген төзүгә һәм «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенә һөнәри әзерлек программалары буенча укытуга субсидия рәвешендә грант бирү турында» 2023 ел, 23 август, 1008 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2023 елда туристлык тармагының кадрлар потенциалын үстерү үзәген төзүгә һәм һөнәри әзерлек программалары буенча укытуга грант алучы турында белешмәләрне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

әлеге карар белән расланган 2023 елда туристлык тармагының кадрлар потенциалын үстерү үзәген төзүгә һәм «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенә һөнәри әзерлек программалары буенча укытуга субсидия рәвешендә грант бирү тәртибенең 13 пунктында «10 эш көненнән соңга калмыйча» сүзләрен «30 эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 23 август, 1008 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 3 ноябрь, 1418 нче
карары редакциясендә)

2023 елда туристлык тармагының кадрлар потенциалын үстерү үзәген төзүгә һәм һөнәри әзерлек программалары буенча укытуга грант алучы турында белешмәләр

| Грант алучы исеме | Грант күләме, сум |
|---|---|
| «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе | 14 008 346,96 |